ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ПУЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423730, Пучы авылы, Киров урамы,
1 нче йорт. Тел.3-44-51.

СОВЕТ ПОИСЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423730,село Поисево, улица
Кирова,дом 1. Тел. 3-44-51.

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**№ 12** **03.07.2020 ел.**

## Актаныш муниципаль районы Пучы авыл җирлегенең кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге кануннарга туры китерү максатларында Актаныш муниципаль районының Пучы авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районының Пучы авыл җирлеге Советының «Актаныш муниципаль районының Пучы авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» 05.10.2007 ел 21.2.1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а. 1 нче кушымтаның 9 пунктындагы 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «5) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, моңа хезмәт шартнамәсенең (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклары керми;».

2. Актаныш муниципаль районының Пучы авыл җирлеге Советының «Актаныш муниципаль районы Пучы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә яңа редакциядә» 07.09.2017елгы 20 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а. Нигезләмәләнең 3.3 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, моңа хезмәт шартнамәсенең (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклары керми;».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Пучы авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Пучы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Башлык Н.З. Нуртдинов